| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25 мая 2023 г. с. Шалты № 9

Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының “Шалты авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгын хайваннарның элеккеге яшәү урыннарына хуҗасыз хайваннарны кайтару турында Карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артымнан калдырам.

Җитәкче З.Х. Фаткуллин